ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 октябрь 2025ел № 8167

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 7 октябрендәге 5357 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 7 октябрендәг 5357 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2024 елның 19 мартындагы 1722 номерлы, 2024 елның 5 сентябрендәге 5722 номерлы, 2025 елның 14 мартындагы 1978 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасы чараларын финанслауны шәһәр бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Халыкны социаль тәэмин итү» 10.03 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 8 974,99 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 349,55 мең сум, 2024 ел – 703,03 мең сум, 2025 ел – 7 922,41 мең сум.»;

2) «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганагы | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 (мең сум) | 2024 (мең сум) | 2025 (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 349,55 | 703,03 | 7 922,41 | |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 349,55 | 703,03 | 7 922,41 | 8 974,99 |

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга программаны финанслау күләме 8 974,99 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2023 ел – 349,55 мең сум, 2024 ел – 703,03 мең сум, 2025 ел – 7 922,41 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.»;

- программага кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 9 октябрендәге
8167 номерлы карарына
кушымта

«2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасына
кушымта

Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Чаралар исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2022 (база) | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Максатның исеме: коммерцияле булмаган оешмаларның социаль юнәлешле эшчәнлеген һәм аларның Яр Чаллы шәһәрен социаль-икътисадый үстерүдә, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ бердәмлекне саклауда катнашуын стимуллаштыру, социаль сәясәт нәтиҗәлелеген һәм халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын күтәрү, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр балансы нигезендә иҗтимагый килешүне тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: 1. СЮКБОга мөлкәт, финанс, мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтү механизмнарын үстерү | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Патриотик тәрбия өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025 | Чаралар саны | - | - | - | 5 тән ким түгел | - | - | 7 203,30 |
| 2. | Махсус хәрби операция ветераннарына, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына социаль характердагы хезмәтләр, консультацияләр, матди ярдәм, психологик ярдәм күрсәтү, аларны реабилитацияләүдә булышлык итү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025 | Хезмәтләр саны | | | | 300 дән ким түгел | - | - | |
| 3. | Торак булмаган бүлмәләрдән түләүсез файдалану шартларында СЮКБОга мөлкәт ярдәме күрсәтү | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе | 2023-2025 | СЮКБО саны | 20 | 20 | 20 | 20 | - | - | - |
| 4. | СЮКБОга торак булмаган бүлмәләр өчен аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташламалар бирү | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе | 2023-2025 | СЮКБО саны | 3 | 3 | 3 | 3 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Элемтә чараларыннан файдаланган өчен чыгымнарны компенсацияләү, иҗтимагый оешмаларның коммуналь түләүләрен каплау | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2023-2025 | Оешмалар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 99,55 | 453,03 | 469,11 |
| 6. | Дәүләт ярдәме алучы СЮКБО реестрын алып бару | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2023-2025 | СЮКБО саны | 40 | 42 | 44 | 45 | - | - | - |
| Бурычның исеме: 2. Массакүләм мәгълүмат чараларында СЮКБО эшчәнлеген популярлаштыру | | | | | | | | | | | |
| 7. | Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында СЮКБО эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2023-2025 | Басмалар саны | 6 | 10 | 10 | 10 | - | - | - |
| 8. | Башкарма комитет вәкилләре белән берлектә СЮКБОның эш очрашуларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2023-2025 | Очрашулар саны | 3 | 4 | 4 | 4 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын уткәру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2023-2025 | Конкурслар саны | - | 1 | 1 | 1 | 250,0 | 250,0 | 250,0 |
| Бурычның иseme: 3. СЮКБОга өстәмә белем бирүне үстерү, сәламәт яшәү рәвешен һәм массакүләм спортны популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча шәһәр чаралары үткәрүдә ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | |
| 10. | Спорт төрләре буенча ярышларга әзерлек һәм аларны үткәрүдә СЮКБОга физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт юнәлешендә консультация һәм оештыру ярдәме күрсәтү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2023-2025 | Мөрәҗәгатьләр саны | 20 | 20 | 20 | 20 | - | - | - |
| Бурычның исеме: 4. СЮКБОның гражданнарның үз-үзләрен тоту буенча социаль куркыныч формаларын профилактикалауга, авыр тормыш хәлендә булган затларны социаль реабилитацияләүгә юнәлдерелгән эшчәнлегенә ярдәм формаларын камилләштерү | | | | | | | | | | |
| 11. | СЮКБО ягыннан халыкның аерым төркемнәренә (наркотик кулланучыларга, мигрантларга һ.б.) социаль-психологик һәм медицина ярдәме күрсәтү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2023-2025 | Күрсәтелгән хезмәтләр саны | 850 | 850 | 850 | 850 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | Бәйлелеккә дучар булган гражданнар өчен социаль-психологик хезмәтләр күрсәткәндә СЮКБОга мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2023-2025 | Кеше саны | 250 | 250 | 250 | 250 | - | - | - |
| | Барлыгы: | | | | | | | | 349,55 | 703,03 | 7 922,41 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ★ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева